2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авылы җирлеге Иске Михайловка авылы гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫКАРАРЫ

2 декабрь 2025 ел №12

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында гражданнар җыеныкарар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаиләәгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм норматив хәлгә китерү).

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, тезү һәм ремонтлау (су җыю манарасын һәм аңа комплектлаучы әйберләрне сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү торбаларын һәм аларга комплектлаучы әйберләрне сатып алу һәм алыштыру).

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Мәктәп урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин